Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Сарабиккол торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сарабиккол авыл җирлеге Сарабиккол торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балачактан һәм 1 төркем инвалидлар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1. халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

-Такташ урамындагы иске агачларны кисү;

- Такташ урамына балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру;
- үсентеләр (чәчәкләр) сатып алу.

2. җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы оештыру:

-“Тегермн чишмәсе " чишмәсен, аңа якын территорияне капиталь ремонтлау һәм төзекләндерү;

-Сарабиккол авылы территориясендә кул белән үлән чабу,

-МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы, май, фильтр сатып алу),

- тракторчы хезмәтенә килешү буенча түләү (территорияне коры һәм чүп үлəненнән чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сукалау, башка эш төрләре),
- карны чистарту өчен асылмалы җиһазлар сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сарабиккол авылы Киров урамы 4А,йортта - хакимият бинасында, Киров урамы 3А - гомуми

белем бирү мәктәбе бинасында, Пионер урамы 45 йорт - «Сатурн - Урал» ҖЧҖ адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүчә,
Лениногорск муниципаль районы
«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Гаделшина